ГЛАВА ЯМБУЛАТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯМБУЛАТ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

03.11.2022 ел с.Ямбулатово № 3

Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлегенең Ямбулат авылында гражданнарның үзара салымы чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлегенең 24 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 елның 19 ноябренә Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлегенең Ямбулат авыл гражданнары арасында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлеге Ямбулат авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

— Ямбулат авылындагы җәяүлеләр күперенә якынлашу өчен тротуар салу.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Авыл мәдәният йорты бинасы янында түбәндәге адрес буенча халык җыенын үткәрергә: Крестниково авылы, Казан урамы, 2А урамы, 12.00 сәгатьтә.

4. Ямбулат авыл җирлегенең Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Ямбулат авыл җирлеге башлыгы А.Н.Макаров